| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.09.2019 Казан шәһәре № 5-6/тэ

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «ПЭСТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган җылылык энергиясен тапшыру хезмәтенә тарифлар билгеләү турында» 2019 елның 26 апрелендәге 5-1/тэ номерлы карары кушымтасына үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең 2019 елның 3 сентябрендәге 31/76912/19 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «ПЭСТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган җылылык энергиясен тапшыру хезмәтенә тарифлар билгеләү турында» 2019 елның 26 апрелендәге 5-1/тэ номерлы карары кушымтасына, аны яңа редакциядә бәян итеп (кушымтада бирелә), үзгәреш кертергә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис в.б. А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 26.04.2019 № 5-1/тэ карарына кушымта «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.09.2019 № 5-6/тэ карары редакциясендә)

«ПЭСТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан
җылылык энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы | Тариф төре | Ел | Җылылык китерү матдәсенең төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Су | Пар |
| | Яшел Үзән муниципаль районы, Осиново авыл җирлеге | | | | |
| 1 | «ПЭСТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/Гкал | карар үз көченә кергәннән алып 31.12.2019 кадәр | 132,77 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге